КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 3 март г.Казань № 194

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июнь, 251 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче; 2021 ел, 3 февраль, 47 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлекләре» сүзләрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия-ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарының 1 һәм $1^1$ пунктларында күрсәтелгән

гражданнарның аерым категорияләренә (алга таба – шул ук эзлеклелектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 192 нче карары, гариза бирүчеләр) билгеләнә.»;

5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) гариза бирүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 192 нче карарындагы 1 һәм $1^1$ пунктларында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә керүен раслый торган документлар (белешмәләр);»;

7 һәм 8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон рәвештә субсидия-ташлама бирү турында карар кабул итү өчен вәкаләтле оешмалардан түбәндәге кирәкле белешмәләрне ала:

яшәү (булу) урыны буенча теркәлү турында;

гариза бирүчегә пенсия билгеләү турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булу (булмау) турында;

гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булу (булмау) турында;

гариза бирүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларыннан файдалануы турында.

Гражданнар Үзәк бүлегенә үз инициативасы белән бу пунктта күрсәтелгән белешмәләр бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.

8. Гариза бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылып, бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән белешмәләр алынганнан соң, Үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән субсидия-ташлама билгеләү турында гариза теркәүгә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итә. Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган белешмәләр кермәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

Гариза бирүчегә субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында хәбәр итү субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булган очракта, субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү иң күбе 90 көнгә туктатып торыла һәм әлеге срок эчендә гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булмавы

турында белешмәләр алынганда йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганда яңадан билгеләнә.

Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакындагы карар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә салымнар һәм җыемнар буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычның булуын (җайга салынуын) раслый торган документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә.

Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакында кабул ителгән карарны хәбәр итү субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан ташлама субсидия билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.»;

9 пунктта:

дүртенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булу;

гариза бирүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларыннан файдалануы.»;

10 пунктның икенче абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

$11^1$ пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$11^1$. Гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булганда, субсидия-ташлама бирү әлеге бурычның булмавы- турында белешмәләр алынганга кадәр туктатып торыла.»;

икенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия-ташлама бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 192 нче карарындагы 1, $1^1$ пунктларында каралган вазыйфаларны биләгән гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе яки муниципаль мәгариф оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылу (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 192 нче карарындагы 1, $1^1$ пунктлары нигезендә субсидия-ташлама бирелә торган очраклардан тыш);

гариза бирүченең үлеме;

алучыга субсидия-ташлама бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән 90 көн эчендә гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салым һәм җыемнар буенча бурычның җайга салынмавы;

гариза бирүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларыннан файдалануы;

гариза бирүче яшәү урынын алмаштыру.»;

түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункт өстәргә:

«$13^1$. Субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә субсидия-ташлама бирүне туктатып торуга (яңадан билгеләүгә) китерә торган вакыйгалар барлыкка килү турында мәгълүмат алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге мәгълүмат бирелгән документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә. Субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» сүзләрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның икенче абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

$2.2^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2[1]. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә, субсидия-ташлама билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

яшәү (булу) урыны буенча теркәлү турында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алу турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милек хокукы турында;

инвалидлык билгеләү факты турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булу (булмау) турында;

бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада төрләр исемлеге күрсәтелгән физик затлар керемнәре турында;

гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булу (булмау) турында.

Гражданнар Үзәк бүлегенә үз инициативасы белән бу пунктта күрсәтелгән белешмәләр бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

2.3 пунктта:

икенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу Нигезләмнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурычы булган очракта, субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү иң күбе 90 көнгә туктатып торыла һәм әлеге срок эчендә гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булмавы турында белешмәләр алынганда йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганда яңадан билгеләнә.

Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) турындагы карар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычның булуын (җайга салынуын) раслый торган документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә. Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакында кабул ителгән карар турында хәбәр итү субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә,

электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.»;

унөченче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булу.»;

2.4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булганда, субсидия-ташлама бирү әлеге бурычны түләп бетерү турында белешмәләр кергәнгә кадәр туктатып торыла.»;

бишенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар мәгълүмат ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә субсидия-ташлама бирүне туктатып торуга (яңадан билгеләүгә) китерә торган вакыйгалар барлыкка килү турында мәгълүмат алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге мәгълүмат бирелгән документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә. Субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү турында» 2018 ел, 22 август, 680 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 декабрь, 1105 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү өчен кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибе турындагы нигезләмә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының өченче абзацында «салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.3 пунктта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурыч булу (булмау) турында.»;

2.5 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу Нигезләмнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булган очракта, компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү иң күбе 90 көнгә туктатып торыла һәм әлеге срок эчендә гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булмавы турында белешмәләр алынганда йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганда яңадан билгеләнә.

Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) турындагы карар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурыч булу (булмау) турындагы белешмәләр алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге бурычның булуын (җайга салынуын) раслый торган документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итүне туктатып тору (яңадан билгеләү) хакында хәбәр итү компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан компенсация билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.»;

2.7 пунктта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Компенсация бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар мәгълүмат ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә компенсация бирүне туктатып торуга (яңадан билгеләүгә), туктатуга китерә торган вакыйгалар барлыкка килү турында алынган йә гариза бирүче тарафыннан әлеге мәгълүмат бирелгән документлар тапшырылган көннән биш эш көне эчендә кабул ителә. Компенсация бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү компенсация бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан компенсация билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.».

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә (2022 елның 1 июленнән үз көченә керә торган 3 пунктның җиденче һәм сигезенче абзацларыннан тыш) кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин